# Татар халкының туклану культурасы белән бәйле лексика: рухи һәм матди аспект[1]

*Нурмөхәммәтова Р.С., Казан, КФУ, филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Саттарова М.Р., Казан, КФУ, филология фәннәре кандидаты, доцент*

Кешелек яшәешенең бүгенге көне глобальләшү, берләшү процессы кичергән шартларда тормыш-көнкүрешнең рухи аспектын яңа сулыш белән, кеше шәхесен үзәккә куеп өйрәнү алгы планга чыга. Кеше мәдәниятара бәйләнешләрдә компетентлы булырга, ягъни аралашуда үз халкы һәм бәйләнешкә кергән якның ритуаллаштырылган дискурс формаларын белергә, аларны дөрес файдаланырга тиеш. Үз халкында кагыйдә буларак кабул ителгән коммуникация тәртибе бозылу теләсә нинди лингвомәдәният вәкиле тарафыннан адекват булмаган аралашу буларак кабул ителә [Алефиренко 2010: 31].

Аралашу, һәртөрле эчтәлектәге мәгълүмат алышу бер үк һәм төрле халык вәкилләре арасында беренче чиратта телдән һәм язма рәвештә башкарыла. Шул ук вакытта җәмгыятьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре дә бу аралашуның мөһим өлешен тәшкил итә. Әлеге аралашуны бер төшенчә – “мәдәният” белән бәйләп карарга мөмкин. Кешелек тарихында “мәдәният” төшенчәсе – җитди һәм үзенчәлекле эчтәлеккә ия булган әһәмиятле берәмлек.

Мәдәният термины күп төрле аңлатмаларга ия. Эчтәлеге белән ул капма-каршы булган “консерватив – туплау, саклау” һәм “прогрессив – үсү, үзгәрү” мәгънәләрен аңлата. Мәдәниятны аерым бер кешенең/гаиләнең яки халыкның/җәмгыятьнең тормыш-көнкүреше буларак аңларга мөмкин. Шул ук вакытта мәдәният вакытка һәм пространствога да бәйле, кешенең үз-үзен тотышы, фикерләве, аны чолгап алган сәнгать әсәрләре, эш кораллары һ.б. аркылы ачыла.

Мәдәният этнография, антропология, фәлсәфә, социология, тарих һ.б. фәннәрнең өйрәнү объекты булып тора. Тел белеме күзлегеннән караганда, мәдәниятнең тел материалында чагылышын ачыклау кызыклы. Вакытлар үтү белән телдә халыкның, җәмгыятьнең рухи халәте теркәлә бара. Мәдәниятара бәйләнешләрдә телнең нәкъ менә шул мөмкинлеге кыйммәткә ия. Беренче карашка килеп чыгышы, элеккеге мәгънәләре нинди булганлыгын уйламыйча да көндәлек сөйләмдә кулланыла торган лексик берәмлекләрнең этимологиясен ачыклау, аларның һәртөрле сүзлекләрдә, паремияләрдә теркәлүен өйрәнү халыкның тулаем рухи, матди халәтен ачыкларга, алай гына да булмыйча, аерым чорларга караган спецификасын күрергә ярдәм итә. Фән буларак формалашып килгән лингвокультурология лексиканы нәкъ менә шул күзлектән тикшерә, гомумиләштереп әйткәндә, мәдәният белән тел бәйләнешен өйрәнә.

Тел үзе иҗтимагый күренеш, аралашу чарасы булу белән беррәттән, халыкның рухи һәм матди мәдәниятен гәүдәләндерә торган кыйммәтләрне белдергән төшенчәләрне туплый һәм буыннан буынга тапшыра. Лингвокультурология күзлегеннән телне танып белү механизмы итеп кенә кабул итү дөреслеккә туры килеп бетми. Һәр мөстәкыйль фәннең үзенә хас тикшеренү методлары, ягъни теоретик һәм гамәли эшчәнлекне оештыруда кулланыла торган принциплар һәм алымнар системасы була. Лингвокультуролгия фәненең дә үз методлары бар. Дөрес, әлеге мәсьәләгә карата тел белемендә фикер төрлелеге күзәтелә. Мәсәлән, Н.Ф.Алефиренко фән буларак лингвокультурология төрле лингвомәдәни берәмлекләрне вакыт аралыгында чагыштырма анализлауны күз алдында тота торган диахрон метод; бер үк вакытта яшәгән лингвомәдәни берәмлекләрне чагыштырып өйрәнә торган синхрон метод; мәдәният объектын өлешләргә бүлү һәм шул өлешләр арасындагы бәйләнешләрне ачыклауны күз алдында тота торган структур-функциональ метод; лингвомәдәни фактның килеп чыгышын, үзгәрүен өйрәнүгә юнәлдерелгән тарихи-генетик метод; тарихи-мәдәни процессның төрле лингвомәдәни берәмлекләренең типологик якынлыкларын ачыклауга хезмәт итә торган типологик методларга таяна дип саный [Алефиренко 2010: 39].

В.А.Маслова фикеренчә, тел һәм мәдәният бәйләнешләрен анализлауда кулланыла торган барлык алым, процедуралар лингвокультурология методларын тәшкил итә. Интегратив өлкә буларак лингвокультурология культурология, тел белеме, этнолингвистика, иҗтимагый (мәдәни) антропология фәннәренең эзләнү, өйрәнү нәтиҗәләренә нигезләнә. Шул сәбәпле, “тел һәм мәдәният” төшенчәләрен үзәккә куйган танып белү методларын комплекслы рәвештә, ә лингвистика һәм культурология методларын сайлап алып куллану кирәк. Шул очракта гына тел белеме яки культурология өлкәсенә караган фәнни-тикшеренү методлары берсе икенчесен тулыландыра [Маслова 2001: 34]. Автор тел материалының эчтәлеген өйрәнү өчен – контент-анализ, мәгънә чикләрен билгеләү өчен – фрейм анализы, интерпретацияләү мөмкинлекләрен ачуда – нарратив анализ, интервью, кыр этнографиясе, мәдәниятне лингвистик реконструкцияләү методларын кулланырга тәкъдим итә. Шул ук вакытта тел белүче информантны мөһим чыганак буларак файдалануга да игътибар юнәлтә.

---

[1] Работа поддержана грантом РГНФ № 11-14-16029а/В

Тасвирланган фикерләрдән аңлашылганча, лингвокуль-турология фәне, аның өйрәнү объекты, методологик нигезе тулысынча формалашып беткән дип санарга иртәрәк. Бигрәк тә лингвокультурология фәненең башка фәннәр белән кисешү нокталары игътибарны җәлеп итә һәм фәнни эзләнүләр сорый. Алга таба каралачак материал бу фикерне раслый.

Иҗтимагый антропология фәне мәдәният төшенчәсен материаль объектлар, идеяләр, кыйммәтләр, тарихи планда барлык чорларга бәйле рәвештә кешенең үз-үзен тотышының төрле формаларда һәм модельләрдә чагылышы буларак кабул итә. Лингвокультурология фәне өчен иҗтимагый антропология фәненең өйрәнү объекты буларак кешенең үз-үзен тотышы, аның эшчәнлеге нәтиҗәләрен өйрәнү әһәмиятле. Кеше белән бәйле барлык гамәлләрнең, күренешләрнең халык өчен кабул ителгән тәртибе, культурасы бар. Туклану, киенү, ял итү, эшләү һ.б. культурасы дигән вакытта халык өчен традицион булган тәртипләр күз алдында тотыла. Әлеге мәкаләдә татар халкы өчен гадәти саналган туклану культурасының үзенчәлекләрен белдерә торган лексик берәмлекләрне тасвирлауга берникадәр урын бирелә.

Һәр халыкның традицион тормыш-көнкүреше белән бәйле төшенчәләр шул телнең лексик байлыгы буларак яши. Үз чиратында сүзлек байлыгы формалашу халыкның тарихы, икътисадый хәле, нинди табигый шартларда яшәве, дине белән бәйле. Татар халкының туклану культурасы үзенчәлекле, төрле булу аның ареаль яктан бик зур территориядә таралып яшәве, рухи яктан төрле диннәр тәэсире кичерүе һ.б. шартлар белән бәйле. Әлеге мәсьәлә галимнәрнең игътибарын җәлеп иткән һәм бүгенге көндә дә тулы, эзлекле өйрәнүне сорый.

Татар халкының традицион туклану этикеты, ризыклары хакында, көнкүреш үзенчәлекләре турында мәгълүматлар Н.Прозин (“Татары и татарские деревни”, 1866), В.К.Магницкий (“Несколько данных о мишарях и их селениях”, 1896), Г.Н.Әхмәров (“О языке и народности мишарей”, 1903), М.Гобәйдуллин, К.Гобәйдуллин (“Пища казанских татар”, 1927), Н.И.Воробьев (“Материальная культура казанских татар (опыт этнографического исследования)”, 1930; “Казанские татары: этнографическое исследование дооктябрьского периода”, 1953), Р.Г.Мөхәммәдов (“Татары-мишари”, 1972), Й.Г.Мөхәммәтшин (“Татары-кряшены”, 1977), Р.К.Уразманова (“Современные обряды татарского народа”, 1984), Т.Хәйретдинова (“Названия пищи в татарском языке”, 1993), С.Шәрипов (“Тайны здоровья”, 1996), “Татары” (2001) һ.б. хезмәтләрендә тупланган. Әмма аларны тел белеме күзлегеннән чыгып, лингвокультурологик аспектта анализлау мөһим.

Мордва республикасы территориясендә яши торган татарларның туклану культурасын бүгенге көн күзлегеннән анализлаган автор буларак Н.Н.Щанкинаны күрсәтергә мөмкин. Автор мәсьәләнең тарихи-мәдәни алшартларын билгели, туклану культурасы үзенчәлекләрен ачыклау максатыннан матди мәдәният элементлары буларак савыт-саба атамаларына тукталa. Хезмәтнең икенче өлешендә көндәлек ризык, бәйрәм-йолалар белән бәйле ашамлыклар, туклану этикеты тасвирлана. Әлеге хезмәттә татар халкының бер өлеше генә (Мордва республикасының 12 районында яшәүче татарлар) өйрәнү объекты булып тора. Халыкның туклану белән бәйле культурасын тулаем өйрәнү өчен алга таба да зур хезмәт кую кирәклеге ачык.

Туклану культурасы – сәламәтлекне саклауның төп нигезләреннән берсе. Бүгенге көндә медицина күп төрле юллар белән кешелекнең сәламәтлеген саклау, гомерен озынайту турында кайгырта. Бу мәсьәләне хәл итү юлларын эзләп, хезмәтләр язылa, төрле проектлар эшләнә. Ә халык моны инде күп гасырлар дәвамында гамәлдә кулланган, ул аның өчен гадәти күренеш. Халыкларның төрле табигый шартларда яшәп, җирлегенә бәйле ризыклар белән туклану, аларны төрлечә әзерләү шуны раслый. Бу хакта С.А.Арутюнованың “Основные пищевые модели и их локальные варианты у народов России” мәкаләсендә нигезле фактлар китерелгән [Арутюнова 2001: 10-18].

Лингвокультурологик аспектта анализлаганда татар халкы өчен ризыкның, матди планда нәрсә булуы белән бергә, рухи яктан хәләл булуы да әһәмияткә ия. *Хәләл* сүзе гарәп теленнән кабул ителгән, “1) рөхсәт ителгән, законлы, тулы, аерылгысыз; 2) законлы гамәл” дигән мәгънәне белдерә [АРС 1999: ]. “Рөхсәт ителгән” дигән төшенчә туклануга гына түгел, иҗтимагый, шәхси тормышның барлык өлкәләренә дә карый. Әлеге төшенчәнең капма-каршысы – *хәрәм* “тыелган” дигәнне белдерә.

Гомумән алганда, хәләл ризык рухи һәм матди яктан чиста, сәламәтлеккә зыянлы катнашмалар кушылмыйча әзерләнгән булырга тиеш. Бу төшенчәнең татар кешесе өчен әһәмиятле эчтәлеге Ислам дине белән бәйле. Дөньякүләм таралган әлеге дин кануннары татар халкының матди һәм рухи мәдәниятенең барлык катламнарына да тирән үтеп кереп, үз традицияләрен барлыкка китергән. Ислам кануннары нигезендә тормыш алып баручы кеше өчен *хәләл* сүзе, беренче чиратта, Аллаһ Тәгалә исеме белән чалынган терлек итеннән хәзерләнгән ит ризыкларын күз алдында тота. Татар халкының туклану рационында ит ризыклары элек-электән төп урынны алып торган. Бу аның яшәү шартлары, хуҗалык һәм көнкүреш рәвеше белән турыдан-туры бәйләнгән. Бүгенге татарлар яратып ашый торган *азу, казылык, катлама, кыздырма, тутырган тавык, тутырма, өчпочмак, пәрәмәч* һ.б. ризыклар барысы да югарыда аталган хәләл ит төшенчәсе белән бәйле һәм аларны белдергән лексик берәмлекләр лингвокультурология фәненең өйрәнү объекты булып тора.

*Дуңгыз ите, буып яки электр тогы ярдәмендә үтерелгән терлек ите, үләксә, кан һәм алардан әзерләнгән ризыклар* хәрәм ашамлыклар булып санала. Моннан тыш *аю, юлбарс, арыслан, бүре, карчыга, лачын һ.б. кебек ерткыч хайван һәм кошлар, эт, ишәк, мул, качыр итен, хайваннарның җенес органнарын, эчке секреция бизләрен, үт куыгын, сидек капчыгын* ашау рөхсәт ителми. Югарыда саналган лексик берәмлекләрдән аңлашылганча, Ислам динен тотучы татар халкы өчен туклану культурасының беренче ярусы хәрәм һәм хәләл төшенчәсе белән бәйле. Бүгенге көндә без аралашып яши торган башка халыкларда да үз дини тәгълиматлары, традицияләре белән бәйле аерым ризыкларны куллану тыела.

Көндәлек рационыбызда кулланыла торган тагын бер төр – диңгез ризыклары. Бу төркем беренче чиратта балык итен күз алдында тота. Елга буйларында урнашып яшәү сәбәпле татар халкында балык электән кулланылган. Татар сүзлекләрендә теркәлгән *алабуга, балык, җәен, кара балык, корбан балык, кызыл канат, кырпы балык, опты, сөләйман балык, табанбалык, ташбаш, чабак, чуртан, чөгә, шыртлака* һ.б. кебек лексик берәмлекләр татар телендә электән актив кулланылган. Сәнәгать, мәдәниятара багланышлар үсү белән бәйле рәвештә бүгенге көндә сөйләм телебездә диңгез балыкларын, хайваннарын атый торган сүзләр дә күп очрый. Мәсәлән, *иваси, кальмар, камбала, креветка, макрель, сёмга, скумбрия, тунец, форель һ.б.* шуны раслый.

Ислам дине кануннары буенча диңгез хайваннарының итен хәләл / хәрәмгә бүлү юк. Әмма төрле халыкларда ышанулар белән бәйле рәвештә туклану үзенчәлекләре бар. Бу күренеш татар халкында да очрый. Моңа мисал буларак “ерткыч һәм тәңкәсез балыкларны ашарга ярамый” дигән фикергә нигезләнеп, чуртан, жумба балыкларын ашамауны китерергә була. Моннан тыш дини тыю белән бәйле булмаган “куян итен ризык буларак кулланырга ярамый” дигән фикер дә очрый. М.Н.Тихомирнова Иртыш буе татарларының традицион ризыкларын өйрәнүгә багышланган хезмәтендә Себер татарларында аерым балыкларны ашау тыелу хакында искәртә [Тихомирнова 2005]. *Чуртан, жумба, мәрсин* балыкларын ашауны тыю белән бәйле ышанулар себер халыкларында элек тә булган [www.osetr.delfel.ru]. Бу күренешнең этимологиясен ачыклау, аның Идел буе татарларында да очравын аңларга мөмкинлек бирәчәк. Дини кануннар буенча андый тыюның булмавы бу күренешнең Идел буенда, Себердә Ислам дине таралганчы барлыкка килүенә ишарә итә.

Туклану белән бәйле булган дини традицияләрнең тагын берсе – *ураза* тоту. Ураза сүзе Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә “рамазан аенда таңнан алып кояш батканга чаклы ашамый-эчми тору йоласы” дип шәрехләнә [ТТАС 2005: 610]. Ураза тоту гамәленең барлык мәгънә-эчтәлеген тасвирлау максатын куймаган хәлдә дә аның Ислам дине кануннары буенча тормыш алып бара торган кеше өчен туклану белән бәйле уңай якларын билгеләү мөһим. Беренче чиратта, ураза тоту ашый торган ризыкның күләмен билгеләргә өйрәтә. Ураза тотуның даими рәвештә ел саен кабатланып торуы, төрле вакытка туры килүе организмда матдәләр алмашын җайга салуга ярдәм итә. Пәйгамбәребез хәдисләреннән аңлашылганча, ураза тоткан вакытта туклыклы ризыкларны сәхәр вакытында ашау хәерле булуы аңлашыла, чөнки көн дәвамында энергия күп кирәк; ә ифтарда артык калорияле ризык ашау файдалы түгел. Кеше организмының ураза тоту режимына ияләнүе, чистаруы туклану белән бәйле бу күренешнең файдалы булуын раслый. Ураза тоту башка диннәрдә дә бар, бары аның чикләүләре генә аерыла. Хәзерге татар әдәби телендә әлеге традиция белән бәйле туклануны белдерә торган түбәндәге лексик берәмлекләр кулланыла: *ифтар / ифтар мәҗлесе, сәхәр, ураза һ.б.* Хәзерге вакытта уразаны үзенчәлекле диета буларак аңлатырга омтылулар бар. Шунлыктан *диета*га тукталып үтү дә урынлы булыр.

Диета – шулай ук халыкның туклану культурасы белән бәйле булган төшенчә. Әлеге сүз медицина өлкәсенә карый, грек теленнән кабул ителгән дип санала һәм “туклану режимы” дигәнне белдерә [ТТАС 2005: 144]. Рус теленә кабул ителгән чит тел сүзләре сүзлегендә диета “режим, тормыш рәвеше” дигәнне белдерә һәм ризыкларның туклыклылык, пешерү ысулы, составы ягыннан махсус сайлап алынган рационны күз алдында тота [СИС 2005: 317]. Мондый төр туклану режимы билгеле бер авырулар белән бәйле булу сәбәпле, милли һәм дини үзенчәлек буларак характерланмаса да, бүгенге көндә татар халкы арасында да киң таралган һәм кулланыла. *Диета, тозсыз ризык, майсыз ризык, аз колорияле ризык* кебек лексик берәмлекләрнең актив кулланылуы татар телендә әлеге мәдәни күренешнең ныклы урнаша баруын раслый.

Татар халкында туклану культурасына бәйле күренеш буларак, чит мәдәниятләр тәэсирендә таралган *вегетарианлык* төшенчәсен дә әйтергә кирәк. Вегетарианлык – ит ашамау, яшелчә һәм сөт азыклары белән генә туклану дигәнне аңлата [ТТАС 2005, 113]. Әлеге күренеш кагыйдәләре белән яшәүче кешене ит ашамаучы дип атау гына вегетариан сүзенең эчтәлеген тулысынча ачмый. Татар халкы өчен ят күренеш булу сәбәпле, бу төшенчәне белдерү өчен татар теленең лексик байлыгында башка берәмлекләр кулланылмый.

Татар халкы табигатьнең дүрт фасылы да булган регионда яши. Шул сәбәпле, ризыклар да сезон белән бәйле булып, туклану культурасына йогынты ясамый калмаган. Мәсәлән, татар халкында җәй көне ит ризыклары, кыш, көз көннәренә караганда, азрак әзерләнә. Бу халыкның традицион яшәү

рәвеше, салкыннан, җәйге челләдә эсседән саклану белән тыгыз бәйле булса кирәк. Мәсәлән, кибетләрдә ел әйләнәсе барлык төр продуктларны сатып алу мөмкин булуга карамастан, татар халкының милли һәм дини традицияләренә, гореф-гадәтләренә бәйле ризык атамаларын белдергән лексик берәмлекләрнең бүген дә актив кулланылуы аларның күптәннән популяр булганлыгын, халыкның табигатькә мөнәсәбәтен, дөньяны кабул итү үзенчәлеген чагылдыра. Мәсәлән, көз көне өмә ясап, каз-үрдәк суйган көнне *баш-аяк бәлеше* пешерү, көзге муллыкта *каз, үрдәк каклау, тутырган кабак* әзерләү*;* кыш көне *сызык, туң май* куллану, *кипкән җиләкләрдән, кишердән чәй* пешерү; яз көне *кычыткан, кузгалак*, *бәбәк ашлары,* җәй көне *әйрән, кымыз, катык, сөтле аш һ.б.* сөт ризыклары әзерләү*, кузгалак, юа, балтырган, атлык* кебек кыргый үләннәрне туклану рационына кертү һ.б.

Бүгенге көн күзлегеннән татар халкының туклану культурасын анализлап карасак, ризык муллыгы, төрлелеге, башка халыкларның милли ризыкларын, җирлегебез өчен гадәти булган ашамлыкларны әзерләү ысулларын үзгәртүне актив кулланылышка кертү югарыда санап үтелгән традицияләрне берникадәр боза. Традицияләргә үзгәрешләр керү белән халыкның сөйләм теленә дә берникадәр яңа лексик берәмлекләр өстәлеп, моңа кадәр кулланылышта булганнары төшеп калырга мөмкин. Мәсәлән, *кока-кола, пицца, ролл, суши, ход-дог* һ.б. кебек ризыклар *гөбәдия, бәлеш, сөтле чәй, токмачлы аш* һәм башка милли ашамлык-эчемлекләр белән бергә аларны белдергән сүзләрне дә берникадәр кысрыклап, көндәлек сөйләм телебездә беренче планга чыга. Әлеге мәкаләдә санап үтелгән ризык атамалары татар халкының туклану культурасы төшенчәсе белән бәйле лексик-семантик кырны формалаштыра, шул сәбәпле аларга рухи һәм матди мәдәният үзенчәлекләрен ачыклау максатыннан лингвокультурологик тасвирлама бирү зарур. Әлеге мәкалә сайлап алынган юнәлештә беренче адым булып тора.

Әдәбият

Алефиренко Н.Ф. Лингвокультурология: ценностно-смысловое пространство языка: учеб.пособие. М.: Флинта: Наука, 2010. 288 с.

Арутюнова С.А. Основные пищевые модели и их локальные варианты у народов России // Традиционная пища как выражение этнического самосознания / Отв. ред. С.А.Арутюнова, Т.А.Воронина. М.: Наука, 2001. С. 10-18.

Маслова В.А. Лингвокультурология: Учеб. пособие для студ. высш. учеб, заведений. М.: Издательский центр «Академия», 2001. 208 с.

Осетр. URL: osetr.delfel.ru

Словарь иностранных слов: ок. 5000 слов / И.А.Васюкова. М.: Астрель: АСТ: Транзиткнига, 2005. 988 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Баш.ред.: Ф.А.Ганиев. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

Тихомирова М.Н. Традиционная пища татар среднего Прииртышья во второй половине XIX – первой трети XX вв. / Автореф. дисс. … канд. истор. наук. Омск, 2005.

Щанкина Н.Н. Культура питания татар-мишарей Мордовии. / Автореф. дисс. … канд. истор. наук. Саранск, 2005.